КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 17 март г.Казань № 231

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2017 ел, 21 ноябрь, 893 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2017 ел, 21 ноябрь, 893 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 март, 173 нче; 2019 ел, 6 сентябрь, 789 нчы; 2020 ел, 10 март, 181 нче; 2020 ел, 14 май, 389 нчы; 2020 ел, 30 декабрь, 1247 нче; 2021 ел, 16 июль, 580 нче; 2023 ел, 14 февраль, 145 нче; 2023 ел, 29 март, 372 нче; 2024 ел, 30 декабрь, 1259 нчы; 2025 ел, 25 июнь, 456 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы гаилә фермер династиясе» республика конкурсында җиңүчеләргә – крестьян (фермер) хуҗалыклары башлыкларына премияләр түләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бирү тәртибенең 5.1 пунктында «100,0 мең сум» сүзләрен «114 942 сум» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасының иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалыгы» республика конкурсын уздыру тәртибенең 1.6 пунктында «100,0 мең сум» сүзләрен «114 942 сум» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасының иң яхшы крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы» республика конкурсын уздыру тәртибендә:

1.6 пунктта «100,0 мең сум» сүзләрен «114 942 сум» сүзләренә алмаштырырга;

4.4 пунктның 4.4.9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.9. Конкурска документлар бирү срогына кадәр соңгы хисап датасына «Физик затлар турында шәхсиләштерелгән белешмәләр» дигән 1151162 нче КНД формасы буенча белешмәләр күчермәсе;»;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының иң яхшы рәисе» республика конкурсын уздыру тәртибендә:

1.6 пунктта «100,0 мең сум» сүзләрен «114 942 сум» сүзләренә алмаштырырга;

4.4 пунктның 4.4.8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.8. Конкурска документлар бирү срогына кадәр соңгы хисап датасына «Физик затлар турында шәхсиләштерелгән белешмәләр» дигән 1151162 нче КНД формасы буенча белешмәләр күчермәсе;»;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексында кече хуҗалык итү формаларын үстерү буенча иң яхшы авыл җирлеге башлыгы» республика конкурсын уздыру тәртибенең 1.6 пунктында «100,0 мең сум» сүзләрен «114 942 сум» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин